КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 ноябрь г.Казань № 953

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 июль, 502 нче; 2017 ел, 31 март, 203 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 807 нче; 2018 ел, 23 июль, 581 нче; 2020 ел, 20 июль, 606 нчы; 2021 ел, 28 июнь, 502 нче; 2022 ел, 25 март, 270 нче; 2023 ел, 4 апрель, 398 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт

программасын гамәлгә ашыруга каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсын уздыру комиссиясе составын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Тәрҗемәче: А.М.Сәгыйтова

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 14 декабрь, 943 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 1 ноябрь, 953 нче
карары редакциясендә)

Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсын уздыру комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры, комиссия рәисе |
| Скирда Максим Владимирович | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы, комиссия рәистәше (килешү буенча) |
| Гомзик Илья Александрович | Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары, комиссия секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Галәветдинов Артем Илдархан улы | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Долгов Марат Шамил улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы |
| Ибәтов Мөхәррәм Мансур улы | Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары |
| Ляукин Максим Владимирович | Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Панкратов Алексей Юрьевич | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенең оештыру бүлеге мөдире |
| Сабурская Сәрия Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Сөнгатуллин Марат Бәһрам улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Шәрифуллин Рамил Әнвәр улы | «Россия дәүләт хокук университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Казан филиалы директоры (Казан шәһәре) (килешү буенча). |